ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ  МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
“ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ”

# “СӘЛАМ” УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКТЫНЫҢ КОНТРОЛЬ БӘЯЛӘҮ СИСТЕМАСЫ:

## агымдагы тикшерү һәм йомгаклау контроль эшләре

Казан
2017

ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә бастырыла

ТРМҮИ ректоры Р.Р. Бәдриеваның гомуми редакциясендә

**Төзүчеләре:**
Н.И. Карпухина , Казан шәһәре, 33 нче урта мәктәп укытучысы

**Фәнни редакторы:**
Э.Н.Денмөхәммәтова, Казан федераль университет доценты, филология фәннәре кандидаты

**Рецензентлары:**
Р.Р. Шәмсетдинова**,** ТР Мәгарифне үстерү институты татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре канд, доцент
З.Н. Кириллова, Казан федераль университет доценты, филология фәннәре кандидаты

**© ТРМҮИ, 2017**

**Особенности контроля достижения планируемых результатов по татарскому языку и литературному чтению русскоязычных детей, обучающихся по УМК «Сәлам»**

Управление любым процессом (процессом обучения в частности) предполагает осуществление определенной системы проверки, т.е. контроля эффективности его функционирования. Контроль направлен на получение информации, анализируя которую учитель вносит необходимые **коррективы в** осуществление процесса **обучения.**

Есть определенные требования к организации контроля в учебной деятельности:

- индивидуальный подход;
- систематичность и регулярность проведения контроля на всех этапах процесса обучения;
- разнообразие форм контроля;
- объективность контроля;
- дифференцированный подход.

Соблюдение указанных требований обеспечивает надежность контроля и выполнение им своих задач в процессе обучения.

На различных этапах обучения используются различные виды контроля:

- ✓ предварительный (актуализация прежних знаний);
- ✓ текущий (в повседневной работе);
- ✓ тематический контроль;
- ✓ итоговый контроль (четверть/триместр, полугодие, за год).

Методы контроля обучения:

- ❖ устный индивидуальный контроль (вызов к доске);
- ❖ устный фронтальный контроль (опрос, лаконичный краткий ответ с места);
- ❖ письменный контроль;

Необходимо особо отметить такие методы контроля, как **взаимоконтроль** и **самоконтроль.** Эти виды контроля развивают такие навыки, как справедливость, честность, коллективизм. Взаимоконтроль и самоконтроль должны предшествовать оценке учителя. Основной функцией самооценки и самоконтроля на начальном этапе обучения является определение учениками границ своего знания и незнания, своих потенциальных возможностей.

Контроль учащихся должен быть направлен на выявление **индивидуальной динамики развития** учащихся (от начала учебного года к концу, от года к году) с учетом личностных особенностей и индивидуальных успехов учеников за текущий и предыдущий периоды. Контроль знаний и умений предусматривает выявление **индивидуальной динамики качества усвоения** предмета (языка в нашем случае) учащимся и не допускает сравнения его с другими детьми.

Итак, котроль знаний учащихся является составной частью процесса обучения. Хорошо поставленный контроль позволяет учителю не только **правильно оценивать уровень усвоения** учащимися изучаемого материала, но и **увидеть собственные удачи и промахи.**

Все это мы постарались учесть при создании нашего учебника. Остановлюсь на проверочных уроках, которые есть в каждом модуле. Они проводятся в виде игры, диалогов, монологов, полилогов, индивидуальной работы, работы в парах и командах. Учащиеся не задумываются, не подозревают, что это контрольный урок, что дает им использовать свои знания и свой потенциал. Они выполняют задания, включаясь в игру. Исключается ситуация стресса и испуга, т.к. в игре все равны. Играя, ученики становятся фантазерами, героями произведений, участниками команды, от каждого из которых зависит успех команды, учителями  и т.д. Воспитывается умение внимательно слушать собеседника, стремление активизировать приобретенные речевые умения, формируется более высокий уровень коммуникативных возможностей.

Каждый проверочный урок начинается с повторения пройденной лексики и структур, которые учащиеся усваивали. Первый этап **“Искә төшер!”** можно проводить используя следующие упражнения:

**1. “Цепочка”.** По цепочке  показываются карточки-картинки или карточки-слова. Ученики быстро по цепочке называют слово, кто затрудняется, из цепочки выпадает и отвечает индивидуально, класс может ему помогать.

На данном этапе возможны исправления и помощь.

**2. “Правильно/неправильно”.** Учитель показывает в определенном порядке  картинки и не всегда их правильно называет. Ученики молча записывают 1 - если перевод правильный, 0 – если перевод неправильный. Получится определенный набор нулей и единиц. Например, 1100111010. Из 10 переводов 4 - неправильных. Сюда можно включить карточки со старой, но нужной на этом уроке лексикой.

**3. “Сыйныфташыңны тикшер!”.** В этом упражнении можно повторить нужную на уроке лексику, которой нет на картинках или трудные структуры. Ученики тестируют друг друга, используя карточки, которые сами же готовят.

После подготовительного этапа идут 3-4 задания. Остановлюсь на наиболее любимых видах работ.

- **Игра “Укучылар һәм укытучылар”**  Дети делятся на две группы, причем группу выбирают сами: одни из них “учителя”, другие “ученики”. “Учителя” задают вопросы, “ученики” отвечают. “Учителя” помогают, если “ученики” затрудняются. Потом меняются ролями.
- **“Сөйлә!”**  В этом упражнении помогают вопросы-подсказки. Сильные ученики могут их не использовать.
- **Работа в командах**  Что-то нарисовать (коллаж) и рассказать. Например, город, деревню, время года и т.д. Такого вида задания  воспитывают ответственность за свою деятельность, заставляют и слабо успевающих

учеников подняться до уровня сильных, чтобы не подвести свою команду.

- Есть и другие задания: отгадай загадку (отгадать предмет по описанию), самим придумать загадку; есть аудирование, прослушай и нарисуй; работа с текстом, прочитай и выполни задание и т.д.

Конечно же, в первом классе оценки не ставятся и результаты проверки заносятся в особую таблицу которую учитель готовит зарнанее.

В середине урока можно сделать зарядку.

После нескольких модулей предусмотрены контрольные работы. Они расчитаны на контроль усвоения материала 3-х модулей.

В конце проверочного урока обязательно проводится рефлексия:

- ✓ Как оцениваете свою работу?
- ✓ У кого были затруднения?
- ✓ Какой вид работы понравился?
- ✓ За что вы можете себя похвалить?
- ✓ За что вы можете похвалить своих одноклассников?
- ✓ Кто по-вашему сегодня лучше всех работал?

Похвалите друг друга.

**Основные принципы** данного комплекта, способствующие интенсификации процесса обучения:

- обучение должно быть радостным и легким;
- активизация процесса обучения;
- развитие интереса и мотивации к процессу обучения с использованием сайта, интерактивных игр, флешкарт, песен, ролевых игр и т.д.;
- создание учебных ситуаций, связанных с реальной жизнью;
- организация активного речевого воздействия;
- создание коммуникативного “ядра”;
- поддержание интереса к изучению татарского языка.

Желаем учителям, которые привыкли эффективно работать и идти в ногу со временем, успехов в освоении учебника XXI века!

## 1. “Сәлам” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Уенчыклар, рәсемле карточкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә. Алдагы дәрестә укучыларга бу дәрескә яраткан уенчыкларын алып килергә кушылган була, шунлыктан укучыларның уенчыклары парта өстендә тора.

Укытучы, кайбер укучылар янына килеп, уенчыкка төртеп күрсәтә һәм “Ул кем/нәрсә?” сорауларын бирә. Укучылар уенчык алып килергә оныткан булсалар, укытучы дәресләрдә файдаланган үз уенчыкларын (Мырау, Шаян, Аю-Миша һ.б. яки төрле уенчык ясалган карточкаларны) аларга биреп тора, дәрестә һәр укучының уенчыгы булуны тәэмин итә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм анық җавап һәм сорауларын бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Сүз белән әйт” | 2нче бирем “Таныш” | 3нче бирем “Таныштыр” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Сәлам! Исәнмесез! Исәнме! Хәерле көн! Мин, син, ул. Рәхмәт. Яхшы, бик яхшы, шәп, начар, начар түгел. Хәлләр ничек? Син кем? Ул кем? Бу ... –мы/-ме? Әйе, юк. Сау бул! Сау булыгыз!”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

**1нче бирем**

**“Сүз белән әйт”.** Укытучы укучыларга өйрәнелгән ишарәләрне күрсәтә, укучылар берәм-берәм ишарәнең нәрсә аңлатуын сүз белән әйтеп бирергә тиеш булалар. Мәсәлән: **сәлам, исәнме, исәнмесез, сау бул, сау булыгыз, мин, син, ул, шәп, яхшы, бик яхшы, начар, рәхмәт, әйе, юк.**

**2нче бирем**

**“Таныштыр”.** Укытучы барлык укучыларга да берәм-берәм карточкалар тарата һәм рәсемдәге зат белән таныштырырга куша. Карточкаларны алдан әзерләп куярга кирәк. Мәсәлән: укучы, укытучы, жираф, крокодил, Мырау, Шаян, Карлсон, Барсик, клоун һ.б. Укучылар җавапларын өченче заттан бирергә тиешләр. Мәсәлән:

*Укытучы:* Маша, хәерле көн! (ишарә) *Укучы:* Исәнмесез! (ишарә)
Бу жирафмы? (ишарә) Юк, жираф түгел. (ишарә)
Бу песиме? (ишарә) Әйе, бу песи. (ишарә)
Ул кем? (ишарә) Ул песи. (ишарә)
Хәлләре ничек?Бик яхшы (яхшы, шәп, начар, начар түгел) – (ишарә)
Сау бул! (ишарә) Сау булыгыз! (ишарә)

### 3нче бирем

**“Таныш”.** Укытучы укучыларга үз уенчыклары роленә керергә куша. Укучылар, парлашып, такта янына чыгалар һәм уенчыклары белән танышалар. Алар уенчык булып сөйләшәләр.

*1 нче укучы:* Исәнме! Син Катямы? *2 нче укучы:* Хәерле көн! Юк, мин Катя түгел.

Син кем? Мин Барби. Ә син Мыраумы?

Мин Мырау түгел. Мин Барсик. Хәлләр ничек? Шәп. Хәлләр ничек?

Бик яхшы. Сау бул! Сау бул!

Һәр укучы такта янына чыгарга тиеш. Парларга бәяләрне укучылар үзләре куя. Укытучы укучылардан ишарәләр ярдәмендә сыйныфташларының җавапларын бәяләүне сорый. Укучылар “яхшы”, “бик яхшы”, “шәп”, “начар” ишарәләрен күрсәтә алалар.

Укытучы нәтиҗәләрне таблицага тутыра.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз? (ишарә)
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз. (ишарә)

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша, уңышлар тели.

## 2. “Мәктәп” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

1нче бирем өчен карточкалар, 2нче бирем өчен карточкалар җыелмасы, буяу карандашлары, ак зур кәгазь (ватман яки А3 форматтагы кәгазь).

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Сүзләрне яхшы бел” | 2нче бирем “Аудирование” | | | 3нче бирем “Рәсем белән эш” | | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | коллаж | төзәтү | өстәмә сүз | командада эшләү | Сорау бирү | | |
| | | | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, **-** хата булу

**“Искә төшер”.** 1) Укытучы алдагы дәресләрдә үтелгән лексик берәмлекләрнең рәсемнәре булган карточкалар күрсәтә, укучылар, кул күтәреп, тиз генә сүзне әйтергә тиеш булалар: **такта, сыйныф, көндәлек, китап, урындык, акбур, чүпрәк, дәфтәр, каләм, бетергеч, өстәл.**

Укытучы кайвакыт кул күтәрмәгән укучыдан да сорый ала. Рәсемнәр урынына укытучы сыйныфтагы предметларны да күрсәтә ала.

2) Укытучы укучыларга рәсемле карточкалар күрсәтә һәм сорау бирә: **“Кайда?”**. Һәр укучы карточкадагы сүзгә карап, җавабын һәм тәрҗемәсен әйтеп чыгарга тиеш була. Мәсәлән: такта рәсеменә карап “такта**да** – на доске”, сыйныф рәсеменә карап “сыйныф**та** – в классе” ди.

3) Тагын монда “бар, юк, түгел, ул, алар”сүзләрен кабатлап китәргә кирәк.

## 1нче бирем

**“Сүзләрне яхшы бел”.** Укучылар дүртәрләп командаларга бүленәләр. Өстәл тирәли басалар. Һәр укучыга өйрәнелгән лексика урын алган 4-5 карточка бирелә. Укучылар рәсемнәрне күрмиләр, карточкаларны арткы як белән тоталар. Чиратлашып, карточкаларны рәсемле ягы белән өстәлгә куялар һәм предметларны берлектә һәм күплектә әйтәләр. Мәсәлән: такта – такта**лар**, каләм – каләмнәр. Укучы сүзне белмәсә, аның йөреше башка укучыга күчә. Кайсы укучы барлык сүзләрне дә дөрес әйтеп, барлык карточкаларын да өстәлгә куеп бетерә, шул җиңүче була, аны барысы да котлый. Укучылар барлык карточкаларын да өстәлгә куеп бетергәнче, уен дәвам итә. Сүзне оныткан укучылар, иптәшләрендәге шул ук карточканы күргәч, исләренә төшерергә һәм үз йөрешләрендә карточкаларын өстәлгә салырга тиеш булалар.

Укытучы укучыларның эшен бәяләп бара.

## 2нче бирем

**“Аудирование”.** Укытучы һәр командага (яки һәр укучыга) билгеле бер лексик берәмлекләрдән торган карточкалар җыелмасы бирә. Һәр команда җыелмасында башкаларныкыннан аерыла торган 4 карточка була (яки һәр укучының җыелмасында 1 карточка), һәр укучыга берәр карточка. Мәсәлән: җыелмага керә торган сүзләр – **өстәл, чүпрәк, такта, каләмнәр, урындык, көндәлек** + 4 рәсем аерылып тора. 1нче командага: укучы, пенал, маркер, дәфтәр рәсемнәре. 2нче командага: бетергеч, укытучы, Мырау, дәфтәрләр рәсемнәре. 3нче командага: карандашлар, акбур, папка, Маша рәсемнәре. 4нче командага: телефон, китап, Шаян, сыйныф рәсемнәре.

Укытучы укылган текст буенча укучыларга әлеге рәсемнәрдән коллаж төзергә куша. Текстны укытучы укый. Мәсәлән:

- Бу **өстәл** (укучылар өстәл рәсемен партага куярга тиеш булалар).
- Өстәлдә **чүпрәк** бар (өстәл рәсеме өстенә чүпрәк рәсемен куялар).
- Бу **такта** (өстәл янына такта рәсемен куялар).
- Тактада чүпрәк юк, **каләмнәр** бар (тактага каләмнәр рәсемен куялар).
- Бу **урындык**. Урындык өстәлдә (урындык рәсемен өстәлгә куялар).
- Урындыкта **көндәлек**. Өстәлдә көндәлек юк (көндәлек рәсемен урындыкка куялар).

Укытучы коллажларны тикшерә. Укучылар үз коллажларының дөреслеген тактадагы рәсем белән чагыштыра (дөрес рәсемне интерактив тактага да чыгарырга мөмкин).

Укытучы укучылардан нәрсәнең дөрес булмавын сорый. Коллажны дөресләргә һәм әйтергә куша. Укучылар: “Урындык өстәлдә түгел. Көндәлек өстәлдә.” һ.б. әйтергә тиеш.

Шуннан соң артык карточкаларны кайда куярга кирәклек сорала, һәм һәр укучы аны әйтергә тиеш була. Мәсәлән: укытучы сыйныфта, папка урындыкта, акбур тактада һ.б. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**Знче бирем**

**“Рәсем белән эш”.** Һәр командага зур кәгазьгә сыйныф бүлмәсен ясарга тәкъдим ителә. Командадагы һәр укучы кәгазьнең төрле почмагында сыйныфтагы предметларны ясый (сызым рәвешендәге рәсем булса да ярый) билгеле бер вакыт эчендә (мәсәлән, 5-7 минутта). Вакыт үткәч, такта янына чыгып, команданың һәр әгъзасы нәрсә ясавын, аның кайда булуын әйтә (мәсәлән, бу өстәл, ул сыйныфта; бу китаплар, алар өстәлдә; бу карандашлар, алар пеналда һ.б.). Башка командалар сорау бирә ала (мәсәлән: Бу бетергечме? Бетергеч урындыктамы? Бу нәрсә? Ул кайда?). Җаваплар таблицага теркәлә.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган махсус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша, уңышлар тели.

## 3. “Саннар” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, “Укытучылар” һәм “Укучылар” дигән табличкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта ничә укучы бар, ничәсе юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Сана” | | 2нче бирем “Дөрес әйт” | 3нче бирем “Укытучылар һәм укучылар” | | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1-10 кадәр санау | 10-1 кадәр санау | | “Укучы” | “Укытучы” | | |
| | | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун; такта, сыйныф, көндәлек, китап, урындык, акбур, чүпрәк, дәфтәр, каләм, бетергеч, өстәл; Сиңа дүрт яшьме? Сиңа ничә яшь? Миңа ... яшь; Ничә дәфтәр бар? Ничә китап кирәк? Кемгә маркер кирәк? Сиңа банан кирәкме? Кайда өч дәфтәр бар?”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

### 1нче бирем

**“Унга кадәр сана” уены.** Барлык укучылар түгәрәккә баса. Укытучы, 1дән 10га кадәр санауны башлап җибәрер өчен, бер укучының исемен атый. Укучылар рәттән, укытучы билгеләгән тизлек белән, саный башлыйлар. Хата ясаган яки тизлекне бозган (санны озак искә төшергән) укучы уеннан чыга. Түгәрәктә саннарны яхшы белгән укучылар кала икән, аларга “+” билгесе куела, һәм уен 10нан 1гә, кире тәртиптә санау белән, дәвам итә. Уенда түгәрәктән чыкмаган укучы (укучылар) җиңә. Җиңүчене барысы да котлый, “шәп” ишарәсен күрсәтәләр.

**2нче бирем**

**“Дөрес әйт”.** Укучылар командаларга бүленә. Һәр командага карточкалар бирелә. Алар партада укучыларга күренми торган рәвештә яталар. Командадагы һәр укучы, чиратлашып, берьюлы ике карточка ала. Берсе саннар белән, икенчесе актив лексика белән. Мәсәлән: ун каләм, җиде бетергеч һ.б. Карточкалардагы сүзтезмәләрне дөрес һәм тизрәк әйтеп бетергән команда (яки укучы) җиңүче була. Аны барысы да котлый.

**3нче бирем**

**“Укытучылар һәм укучылар” уены.** Укучылар ике командага бүленәләр. Бер команда – “Укучылар”, икенче команда “Укытучылар”. Балалар алдына “Укучылар” һәм “Укытучылар” дигән ике табличка куелып, алар үзләре дә теләгән команданы сайлый ала.

“Укытучылар” “Укучылар”дан үзләре теләгән укучыны сайлап, 1-3 сорау бирәләр һәм укучылардан җавап алалар. Мәсәлән:

- Сиңа дүрт яшьме? (Көтелгән җавап: Юк, миңа дүрт яшь түгел, миңа җиде яшь.)
- Сиңа ничә яшь? (Көтелгән җавап: Миңа да тугыз яшь.)
- Ничә дәфтәр бар? (Көтелгән җавап: Алты дәфтәр бар.)
- Ничә китап кирәк? (Көтелгән җавап: өч китап кирәк.)
- Кемгә маркер кирәк? (Көтелгән җавап: Миңа маркер кирәк.)
- Сиңа банан кирәкме? (Көтелгән җавап: Әйе, миңа банан кирәк./Юк, миңа банан кирәк түгел.)
- Кайда биш дәфтәр бар? (Көтелгән җавап: Өстәлдә/шкафта өч дәфтәр бар.) Һ.б.

Командадагы һәр укучы сорау һәм җавап биреп өлгерергә тиеш. Моны укытучы контрольдә тота. Соңыннан укучылар рольләре белән алышыналар һәм уен дәвам итә.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Кемгә укытучы булырга ошады?
- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

**4. “Төсләр” модуле**

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.
Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.
Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, “Укытучылар” һәм “Укучылар” дигән табличкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

<table>
<tr><th rowspan="2">Укучының исеме һәм фамилиясе</th><th rowspan="2">1нче бирем “Төсләрне бел”</th><th colspan="2">2нче бирем “Сүзтезмәләр”</th><th colspan="2">3нче бирем “Укытучылар һәм укучылар”</th><th rowspan="2">Авазларның әйтелеше</th><th rowspan="2">Нәтиҗә</th></tr>
<tr><th>Рәсемнәрне тоташтыру</th><th>Сүзтез - мәләрне әйтү</th><th>“Укучы”</th><th>“Укытучы”</th></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

\+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Кара, күк, сары, яшел, көрән, кызыл, кызгылт сары, соры, зәңгәр, ак, ал, шәмәхә, матур, күбәләк, чәчәк; нинди? ничә? кайда?; Кофта нинди? Дәфтәр яшелме? Китап кайда? Ничә карандаш яшел? Шәмәхә күбәләк кайда?”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.


1) укытучы укучыларга алдагы дәресләрдә үтелгән лексик берәмлекләрнең рәсемнәре булган карточкалар күрсәтә ала (мәктәп, саннар темасыннан) яки рәсемнәр урынына сыйныфтагы предметларны күрсәтә һәм аларның төсләрен сорый ала.

2) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: матур, ничә? нинди? кайда? зур, кечкенә, төс, нинди төстә? бар, юк һ.б.

Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.

Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.

Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр. Киләчәктә шундый карточкаларны укучылар үзләре ясыйлар. Ясаганда кабатлыйлар һәм истә калдыралар.




**1нче бирем**

**“Төсләр”.** Укытучы төсләрне саннар белән тамгалый. Аларны укучыларга әйтә. Мәсәлән:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1<br>кызыл | 2<br>кызгылт сары | 3<br>зәңгәр | 4<br>кара | 5<br>сары |
| 6<br>соры | 7<br>ак | 8<br>шәмәхә | 9<br>көрән | 10<br>яшел |

Укытучы бер төс әйтә, укучылар шул төснең санын дәфтәрләренә язарга тиеш. Нәтиҗәдә саннар рәте барлыкка килә. Мәсәлән: 7 3 5 2 9 6 4 1 8 10 дигән саннар рәте языла. Җавапларны тикшергәндә, укытучы саннарны татарча атый, укучылар тикшерәләр.

Бер хата да ясамаган укучылар кулларын күтәрәләр. Сыйныфташлары аларны ишарәләр белән бәялиләр. Укытучы укучыларның эшен бәяләп бара. (Ал, күк төсләре юк, чөнки саннар унга кадәр генә.)

**2нче бирем**

**“Сүзтезмәләр”.** Алдагы күнегүдәге принцип буенча, төсләр саннар белән тамгалана. Укучыларга 3-5 рәсемле карточка бирелә. Рәсемнәрдәге предметның төсен укучы сан белән тоташтыра һәм сүзтезмәне әйтергә тиеш була. Мәсәлән: 1) лимон рәсеме бирелә. Укучы дәфтәренә 5 санын яза, җавап биргәндә: “Лимон сары”, - дип әйтергә тиеш була; 2) дәфтәр рәсеме бирелә. Укучы дәфтәренә 10 санын яза, җавап биргәндә: “Дәфтәр яшел”, - дип әйтергә тиеш була; 3) күбәләк рәсеме бирелә. Укучы дәфтәренә 8 санын яза, җавап биргәндә: “Күбәләк шәмәхә”, - дип әйтергә тиеш була һ.б.

Эшне башкару өчен, вакыт билгеләнә. Мәсәлән, 3 минутка таймер куярга мөмкин. Аннан соң һәр укучы барлыкка килгән сүзтезмәләрне әйтеп чыга, ә

калганнары ишарәләр ярдәмендә үзләренең килешү-килешмәүләрен белдерәләр. Укытучы укучылардан нәрсәнең дөрес, нәрсәнең дөрес булмавын сорый. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**3нче бирем**

**“Укытучылар һәм укучылар” уены.** Укучылар ике командага бүленәләр. Бер команда – “Укучылар”, икенче команда “Укытучылар”. Балалар алдына “Укучылар” һәм “Укытучылар” дигән ике табличка куелып, алар үзләре дә теләгән команданы сайлый ала.

“Укытучылар” “укучылар”дан үзләре теләгән укучыны сайлап, 1-3 сорау бирәләр һәм укучылардан җавап алалар. Мәсәлән:

- Кофта нинди? (Көтелгән җавап: Кофта сары түгел, ул кызгылт сары.)
- Дәфтәр яшелме? (Көтелгән җавап: Дәфтәр яшел түгел, зәңгәр.)
- Китап кайда? (Көтелгән җавап: Китап өстәлдә түгел, шкафта.
- Ничә карандаш яшел? (Көтелгән җавап: сигез карандаш яшел.)
- Шәмәхә күбәләк кайда? (Көтелгән җавап: Шәмәхә күбәләк кызыл чәчәктә.) Һ.б.

Командадагы һәр укучы сорау һәм җавап биреп өлгерергә тиеш. Моны укытучы контрольдә тота. Соңыннан укучылар рольләре белән алышыналар һәм уен дәвам итә.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 5. “Гаилә” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Тема буенча үткән лексик берәмлекләрне һәм структураларны сөйләмдә дөрес куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Командада һәм күмәк эшли белү.

**Җиһазлар**

1нче бирем өчен карточкалар, рәсемле карточкалар, атрибутлар (мәсәлән: алъяпкыч, эшләпә, газета, күзлек һ.б.)

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Сүзләрне яхшы бел” | 2нче бирем “Сораулар һәм җаваплар” | | 3нче бирем “Тату гаилә” уены | | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Җаваплар | Сораулар | Сөйләү | Рольгә керү | | |
| | | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Гаилә, әти, әни, әби, апа, бабай, сеңел, эне, абый, зур, кечкенә, яшь, карт. Бу әби түгел, бу әни. Әни карт түгел, ул яшь. Минем ... ем/ым/м бар/юк. Синең ... ың/ың/ң бар/юк. Аның ... -сы, -се, -ы, -е бар/юк. Синең ...ың/ең бармы? Әйе, ... бар. / Юк, ике .. -м юк”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:

1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне үрнәк буенча: бу гаилә – гаилә кечкенә түгел, бу әни – әни карт түгел, бу сеңел – сеңел зур түгел, бу бабай – бабай яшь түгел һ.б. әйтергә тиеш. Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.

2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин (саннар, төсләр, мәктәп темасыннан). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.

3) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: кем? кемнәр? ничә?, нинди?, кайда? ничек? исем, матур, карт, яшь, зур, кечкенә, бар, юк, түгел, мин, син, ул, алар һ.б.

Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.

Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.
Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

**1нче бирем**

**“Сүзләрне яхшы бел”.** Укучылар дүртәрләп командаларга бүленәләр. Өстәл тирәли басалар. Һәр укучыга өйрәнелгән лексика урын алган 4-5 карточка бирелә. Укучылар рәсемнәрне күрмиләр, карточкаларны арткы як белән тоталар. Чиратлашып, карточкаларны рәсемле ягы белән өстәлгә куялар һәм үрнәк буенча әйтәләр. Үрнәк: апа – минем апа**м**, әни – минем әни**ем** һ.б. Укучы сүзне белмәсә, аның йөреше башка укучыга күчә. Кайсы укучы барлык сүзләрне дә дөрес әйтеп, барлык карточкаларын да өстәлгә куеп бетерә, шул җиңүче була, аны барысы да котлый. Укучылар барлык карточкаларын да өстәлгә куеп бетергәнче, уен дәвам итә. Сүзне оныткан укучылар, иптәшләрендәге шул ук карточканы күргәч, исләренә төшерергә һәм үз йөрешләрендә карточкаларын өстәлгә салырга тиеш булалар.
Укытучы укучыларның эшен бәяләп бара.

**2нче бирем**

**“Сораулар һәм җаваплар”.** Укытучы рәсемле карточкалар күрсәтә (гаилә, әти, әни, әби, апа, бабай, сеңел, эне, абый) һәм рәсемгә карата сораулар бирә. Мәсәлән:

- апа рәсеме: Синең апаң бармы? Аның исеме ничек? Ул картмы? Ул яшьме? Ул нинди?
- гаилә рәсеме: Синең гаиләң зурмы? Синең гаиләң кечкенәме? Гаиләдә ничә кеше бар? Алар кемнәр? Әни картмы? Аңа ничә яшь?
- сеңел рәсеме: Синең сеңелең бармы? Аның исеме ничек? Ул зурмы, кечкенәме? Ул нинди?

Һ.б. Укучылар җавап бирергә тиеш. Теләгән укучылар үзләре дә сыйныфташларына сораулар бирә ала.

**3нче бирем**

**“Тату гаилә”уены.** Укытучы укучыларны 4-5 кешедән торган командаларга бүлә. Һәр команда гаилә булып уйнарга тиеш була. Команда эчендә гаилә агъзаларын билгелиләр. Әзерләнү өчен укытучы 7-10 минут вакыт бирә. Таймер куярга мөмкин. Атрибутлар да кулланып була, мәсәлән: алъяпкыч, эшләпә, газета, күзлек һ.б. Укытучы команданың һәр әгъзасы да катнашырга тиешлекне һәм темага кагылышлы барлык сүзләрне, гыйбарәләрне кулланырга кирәклеген әйтеп үтә. Гаиләнең һәр әгъзасы, рольгә кереп, үзе белән таныштыра. Мәсәлән:

- Мин малай. Минем исемем Артур. Миңа 7 яшь. Минем әнием бар. Аның исеме Галия. Ул яшь, карт түгел.
- Мин әни. Минем исемем Галия. Мин яшь. Минем улым бар. Аның исеме Артур. Ул зур, яхшы малай.

- Мин кыз. Минем исемем Әлинә. Минем абыем бар. Аның исеме Артур. Минем әнием яшь. Аның исеме Галия.
- Мин әби. Минем исемем Айсылу. Мин яшь түгел, мин карт. Минем кызым бар. Аның исеме Галия. Һ.б.

Сыйныфташлары аларны ишарәләр белән бәялиләр. Укучылар сөйләмен укытучы бәяләп бара. Бу уенны видеога да төшереп була.

**“Бәяләү”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 6. “Уенчыклар” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, уенчыклар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Укучыларга яраткан уенчыклары турында сораулар бирә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Миндә бар/юк”. | 2нче бирем “Саннар-уенчыклар” уены. | 3нче бирем “Миндә уенчык бар” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

\+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **Машина, уенчык, бөтерчек, уен, курчак, туп, шакмак, быргы, робот, барабан, торба, поезд, очкыч. Минем ... бар. Мин ... белән уйныйм. ...-ны алам. Ничә**

**уенчык бар?Уенчык кайда?** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.
Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:
1) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин (мәсәлән: төсләр, саннар темасыннан). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.
2) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: ничә?, нинди?, кайда?, бар, юк, зур өстәлдә, матур бүлмәдә, кечкенә тартмада, курчак белән уйныйм һ.б.
Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.
Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.
Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

## 1нче бирем

**“Миндә бар/юк”.** Укытучы укучыларга рәсемле карточка күрсәтә (туп,бөтерчек, машина, уенчык, курчак, шакмак, робот, барабан, торба, быргы, поезд, очкыч) һәм “Миндә туп бар” ди. Аннары икенче карточка күрсәтә. “Миндә бөтерчек юк” ди. Бу үрнәк буенча һәр укучы укытучы күрсәткән карточкалардагы уенчыкларның үзендә барлыгын яки юклыгын әйтә. Укучылар бер раслау һәм бер инкяр форманы әйтеп чыгарга тиеш булалар. Укытучы укучыларның эшен бәяләп бара.

## 2нче бирем

**“Саннар-уенчыклар”уены.** Һәр укучыга номерлы карточка бирелә. Мәсәлән, 5. Укучы санны татарча әйтә, укытучы өстәле янына килә һәм 5нче сан астында яткан карточканы ала. Карточкада сурәтләнгән уенчык турында сөйли. Кимендә 4-5 җөмлә әйтү сорала. Мәсәлән:

- Бу – курчак. Аның исеме Наташа. Ул матур, кечкенә. Курчак кызыл тартмада. Тартма зур бүлмәдә.
- Болар – шакмаклар. Шакмаклар яшел. Бер шакмак кечкенә. Ике шакмак зур. Алар шәмәхә тартмада. Һ.б.

Сыйныфташлары җавапларны ишарәләр белән бәялиләр.
Укучы читенсенсә, укытучы сораулар бирә яки укучылардан бирдерә һәм нәтиҗәләрне таблицага тутыра.

**3нче бирем**

**“Миндә уенчык бар”.** Һәр укучы үзенә уенчык сайлый. Укытучы дәрескә уенчыклар кирәк буласын алдан әйткән була. Укучылар үзләре һәм уенчыклары турында сөйләргә әзерләнәләр. Һәр укучы үзе һәм уенчыгы белән таныштырырга, уенчыкның кайда булуын әйтергә тиеш. Мәсәлән:

- Исәнмесез! Мин – Катя. Миңа 7 яшь. Мин укучы. Миндә курчак бар. Аның исеме – Настя. Ул кечкенә, матур. Мин курчак белән уйныйм. Настя зәңгәр тартмада.
- Исәнмесез! Мин – Иван. Миңа 7 яшь. Мин укучы. Миндә барабан бар. Ул яңа, матур, кызыл. Ул зур бүлмәдә. Мин барабан белән уйныйм. Һ.б.

Сыйныфташлары аларны ишарәләр белән бәялиләр. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 7. “Шөгыльләр” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, уенчыклар, “Укытучылар” һәм “Укучылар” дигән табличкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Хәрәкәт яса” | 2нче бирем “Хәрәкәтне дөрес әйт”. | 3нче бирем “Укытучылар һәм укучылар” | | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | укытучылар | укучылар | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укытучы кайвакыт кул күтәрмәгән укучыдан да сорый ала. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Бар – ул бара, утыр – ул утыра, бас – ул баса, яз – ул яза, ал – ул ала, чык – ул чыга, әйт – ул әйтә, сөрт – ул сөртә, кер – ул керә, эч – ул эчә, кер – ул керә, кил – ул килә, җырла – ул җырлый, укы – ул укый, аша – ул ашый, уйна – ул уйный, кара –ул карый, тыңла – ул тыңлый, тукта – ул туктый”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:

1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне тиз-тиз әйтергә тиеш. Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.

2) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә дәрестә кулланырга тиеш булган сүзләрне дә кабатларга кирәк: кем? нәрсә? нинди? нишли? кайда? бүлмәдә, мәктәптә, сыйныфта, машинада, тактада, чәчәктә, көндәлектә, өстәлдә, кибеттә, гаиләдә, тартмада h.б.

Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.

Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.

Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

## 1нче бирем

**“Хәрәкәт ясa” уены.** Барлык укучылар түгәрәккә баса. Укытучы бер укучының исемен атый, ул хәрәкәтне белдергән сүз әйтә, башкалар хәрәкәт ясыйлар. Аннары икенче бала сүз әйтә, башкалар хәрәкәт ясый. Чират буенча шулай дәвам итә. Хата ясаган яки тизлекне бозган (сүзне әкренрәк әйткән) укучы уеннан чыга. Уенда түгәрәктән чыкмаган укучы (укучылар) җиңә. Җиңүчеләрне барысы да котлый, “шәп” ишарәсен күрсәтәләр. Укытучы укучыларны бәяли.

## 2нче бирем

**“Хәрәкәтне дөрес әйт”.** Укучылар 4-5 кешедән торган командаларга бүленә. Һәр командага уенчык һәм карточкалар бирелә. Алар партада, карточкалар рәсемнәре укучыларга күренми торган рәвештә яталар. Һәр укучы, чиратлап, карточканы карый һәм шунда ук хәрәкәтне өченче затта әйтергә тиеш. Мәсәлән: Мырау нишли? – Мырау чыга. Мырау ашый. Һ.б. укучы рәсемдә сурәтләнгәнне дөрес әйтмәсә, яки сүзне белмәсә, аның йөреше башка укучыга күчә, карточка кабат партага куела. Карточкаларда сурәтләнгәннәрне дөрес һәм тизрәк әйтеп бетергән команда (яки укучы) җиңүче була. Аны барысы да котлый. Укытучы укучыларның эшен бәяләп бара.

**3нче бирем**

**“Укытучылар һәм укучылар” уены.** Укучылар ике командага бүленәләр. Бер команда – “Укучылар”, икенче команда “Укытучылар”. Балалар алдына “Укучылар” һәм “Укытучылар” дигән ике табличка куелып, алар үзләре дә теләгән команданы сайлый ала.

“Укытучылар” “укучылар”дан үзләре теләгән укучыны сайлап, хәрәкәтләр буенча сораулар бирәләр. Бер “укытучы” хәрәкәт ясый, ә икенчесе сорый. Мәсәлән:

- Саша нишли? Саша кайда? Саша нинди? (Көтелгән җаваплар: Саша яза. Саша дәфтәрдә яза. Саша мәктәптә. Ул яхшы малай.)
- Мырау нишли? Мырау кайда? Мырау нинди? (Көтелгән җаваплар: Мырау утыра. Мырау урындыкта. Мырау кечкенә.)
- Алсу нишли? Алсу кайда? Алсу нинди? (Көтелгән җаваплар: Алсу матур җырлый. Ул мәктәптә. Ул бик яхшы укучы.) Һ.б.

Командадагы һәр укучы сорау һәм җавап биреп өлгерергә тиеш. Моны укытучы контрольдә тота. Соңыннан укучылар рольләре белән алышыналар һәм уен дәвам итә. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 8. “Вакыт” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, буяу карандашлары, ак зур кәгазь (ватман), “Укытучылар” һәм “Укучылар” дигән табличкалар..

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Кояш” | 2нче бирем “Рәсем белән эш” | 3нче бирем “Укытучылар һәм укучылар” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Көз, яз, җәй, кыш, көз көне, яз көне, җәй көне, кыш көне, хәзер, кайчан?, ай, кыш/яз/җәй/көз айлары, төн, төнлә, иртә, иртән, көн, көндез, кич, кичен, төн, төнлә ”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:

1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне тиз-тиз әйтергә тиеш. Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин. Мәсәлән: ял көне, сәгать, саннар һ.б. Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.

2) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: кайчан?, кайда?, кая?, нишли?, нишлисең?, ничәдә? укы – мин укыйм, уйна – мин уйныйм, йокла – мин йоклыйм, кайт – мин кайтам, кара – мин карыйм, бар – мин барам, ял ит – мин ял итәм, тор – мин торам, эч – мин эчәм, ашханә һ.б.

Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.

Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.

Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

### 1нче бирем

**“Кояш”.** Укытучы укучыларга кояш рәсемнәре бирә һәм нурларга вакыт темасына караган сүзләр язарга куша. Соңыннан шул сүзләр белән җөмләләр төзиләр. Мәсәлән: Яз көне җылы була. Төнлә йоклыйлар. Кичен уйныйлар. Хәзер декабрь ае. Көз көне агачлар сары. Яз айлары: март, апрель, май. Җәй көне алмалар кызыл. Һ.б. Бу биремне парлап та, командалап та эшләргә була. Иң матур һәм дөрес җөмләләр әйткән укучыларга алкышлыйлар.

### 2нче бирем

**“Рәсем белән эш”.** Укытучы укучыларны 4-5 кешедән торган командаларга бүлә. Һәр командага зур кәгазьгә көндәлек режимнарын ясарга тәкъдим итәлә.

Командадагы һәр укучы кәгазьнең төрле почмагында  сәгать ничәдә нишләвен ясый (сызым рәвешендәге рәсем булса да ярый) билгеле бер вакыт эчендә (мәсәлән, 7-10 минутта). Вакыт үткәч, такта янына чыгып, команданың һәр әгъзасы нәрсә ясавын, әйтә. Мәсәлән:

- Икедә мин өйгә кайтам.
- Алтыда мин мультфильм карыйм.
- Сигездә мин мәктәпкә барам.
- Өчтә мин урамда уйныйм.
- Унда мин йоклыйм. Һ.б.

Җаваплар таблицага теркәлә.

**3нче бирем**

**“Укытучылар һәм укучылар” уены.** Укучылар ике командага бүленәләр. Бер команда – “Укучылар”, икенче команда “Укытучылар”. Балалар алдына “Укучылар” һәм “Укытучылар” дигән ике табличка куелып, алар үзләре дә теләгән команданы сайлый ала.

“Укытучылар” “укучылар”дан үзләре теләгән укучыны сайлап, 1-3 сорау бирәләр һәм укучылардан җавап алалар. Мәсәлән:

- Син кайчан торасың? (Көтелгән җавап: Мин җидедә торам.)
- Тугызда син нишлисең? (Көтелгән җавап: Тугызда мин мәктәптә укыйм.)
- Кем көндез ашханәгә бара? (Көтелгән җавап: Укучылар көндез ашханәгә бара.)
- Син кайчан ял итәсең? (Көтелгән җавап: Мин кичен ял итәм.)
- Кичен син нишлисең? (Көтелгән җавап: Кичен мин уенчыклар белән белән уйныйм.)
- Кем кичен китап укый? (Көтелгән җаваплар: Әнием кичен китап укый. Мин дә укыйм.) Һ.б.

Командадагы һәр укучы сорау һәм җавап биреп өлгерергә тиеш. Моны укытучы контрольдә тота. Соңыннан укучылар рольләре белән алышыналар һәм уен дәвам итә.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 9. “Шәһәр, авыл” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Тема буенча үткән лексик берәмлекләрне һәм структураларны сөйләмдә дөрес куллана алу.
Үз-үзеңне бәяли белү, башкаларны ишетә һәм тыңлый белү.
Командада һәм күмәк эшли белү, тырышлык, игътибарлык тәрбияләү.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, текст, биремле карточкалар, ватман кәгазьләре, буяу карандашлары.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Текст белән эш” | | | 2нче бирем “Рәсем белән эш” | 3нче бирем “Сораулар” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | уку | сораулар | ялгыш җөмләләр | | | | |
| | | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Шәһәр, авыл, урам, кибет, бина, елга, юл, урман, киң, тар. Син кайда яшисең? Шәһәрдә/авылда нәрсәләр бар?”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:

1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне берлек һәм күплек саннарда тиз-тиз әйтергә тиеш (мәсәлән: урам – урамнар, кибет – кибетләр һ.б.). Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.

2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин. (Мәсәлән: уенчыклар, төсләр, саннар.) Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.

3) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: ничә?, нинди?, кайда?, дуслар, музейга, циркка, театрга, матур, кил – ул килә, йөр – ул йөри, бар – ул бара, ал – ул ала, бүген, шат, кирәк һ.б.

Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.

Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр. Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

**1нче бирем**

**“Текстны белән эш”.** Укытучы укучыларның таныш булмаган текстның эчтәлеген дөрес аңлап, биремнәрен дөрес эшли алуларын тикшерә.

**Акбай белән Сарбай**

Акбай авылда яши. Ә аның дусты Сарбай – шәһәрдә. Акбай бүген шәһәргә килә. Сарбай бик шат. Акбай белән Сарбай театрга, циркка, музейга йөриләр, кибеткә баралар. Кибеттә уенчыклар күп. Акбай ике кызыл туп ала. Сарбайга җиде дәфтәр кирәк. Шәһәрдә бик шәп!

Биремнәр:

Һәр укучы 1) текстны сәнгатьле укый;

2) бер җөмләгә сораулар уйлый, мәсәлән: *Акбай авылда яши.*

Кем авылда яши?
Акбай кайда яши?
Акбай авылда нишли?
Акбай авылда яшиме?

3) текстка туры килмәгән җөмләләрне таба:

- Сарбай авылда яши.
- Сарбай белән Акбай театрга йөриләр.
- Акбай өч яшел туп ала.
- Сарбайга көндәлекләр кирәк.
- Шәһәрдә яхшы.
- Сарбай белән Акбай дуслар.



4) Рәсемдә кем тасвирланганны язалар.

**2нче бирем**

**“Рәсем белән эш”.** Укытучы укучыларны 4-5 кешедән торган командаларга бүлә. Һәр командага зур кәгазьгә шәһәр һәм авыл рәсемен ясарга тәкъдим ителә. Теманы сайлау өчен, укытучы командалар санына карап, Акбай һәм Сарбай төшерелгән карточкаларны рәсемен аска каратып куя. Командалар “Сарбайны” сайласалар, шәһәр рәсемен ясыйлар. “Акбайны” сайласалар – авылны. Командадагы һәр укучы кәгазьнең төрле почмагында темага карата рәсем ясый (сызым рәвешендәге рәсем булса да ярый) билгеле бер вакыт эчендә (мәсәлән, 7-10 минутта). Вакыт үткәч, такта янына чыгып, команданың һәр әгъзасы нәрсә ясавын, әйтә. Мәсәлән:

- Авылда елга бар. Трамвайлар юк. Урамнар тар, киң түгел. Урамда йортлар. Алар кечкенә, зур түгел, бик матур. Авылда кибет бар. Авылда театр юк.
- Бу шәһәр. Шәһәрдә биналар зур. Урамнар тар түгел, киң. Шәһәрдә кибетләр бар. Кибеттә уенчыклар күп. Урман юк. Музейлар бар. Һ.б.

Җаваплар таблицага теркәлә.

**3нче бирем**

**“Сораулар”.** Укытучы командаларга, рәсемнәр белән алышынып, сораулар уйларга тәкъдим итә. Мәсәлән: Авылда елга бармы? Бу кибеттә нәрсәләр бар? Авылда трамвайлар кайда? Шәһәрдә урамнар нинди? Юллар тармы, киңме? Светофор кайда бар, шәһәрдәме, авылдамы? Һ.б. Иң кызыклы сорауларны уйлап тапкан команда җиңүче була. Аңа алкышлыйлар. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 10. “Йорт” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Дәресләрдә кызыксынучан булу, үзеңне һәм башкаларны бәяли белү.

Укытучы һәм сыйныфташлар белән аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, биремле карточкалар, аудирование өчен альбом битләре.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Йортлар” | 2нче бирем “Тест” | 3нче бирем “Тыңла һәм рәсем яса”. | | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | рәсем | сөйләү | | |
| | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Йорт,**

**өй, кат, ишек, тәрәзә, бүлмә, җиһаз, өстәл, урындык, караватт. Йортта нәрсә бар? Бүлмәдә ... бар.”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.


Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:

1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне үрнәк буенча тиз-тиз әйтергә тиеш (үрнәк: тәрәзә – тәрәзәләр – җиде тәрәзә; ишек – ишекләр – ике ишек; бүлмә – бүлмәләр – дүрт бүлмә һ.б.). Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.

2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин. (Мәсәлән: “Мәктәп”, “Уенчыклар”, “Саннар”, “Төсләр” темаларының лексикасын). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.

**1нче бирем**

**“Йортлар”.** Укытучы укучыларга сүзләрне йортларга дөрес урнаштырырга куша. Мәсәлән: бүлмә, курчак, сыйныф, көндәлек, туп, укытучы, шакмак, карават, җиһаз. Бу биремне билгеле бер вакыт өчендә эшләргә тиеш булалар, мәсәлән 5 минут бирелә. Тизрәк һәм дөресрәк эшләгән укучыга алкышлыйлар, ул җиңүче була.




**2нче бирем**

**“Тест”.** Укытучы укучыларга тест ясарга тәкъдим итә. Бу эшкә 5 минут бирелә.

**1. Хәерлә иртә, хәлләр ничек?**

а) тыныч йокы, шәп б) хәерле иртә, яхшы в) хәерле кич, бик яхшы

**2. Син кайда яшисең?**

а) теге йортта б) бу мәктәптә в) зәңгәр тартмада

**3. Өйдә нәрсә бар?**

а) шәһәр б) сыйныф в) урындык

**4. Бүлмәдә нәрсә бар?**

а) авыл б) карават в) кат

**5. Компьютер кайда?**

а) өстәлдә б) дәфтәрдә в) тактада

Вакыт үткәч, укучылар бер-берсен тикшерәләр. Дөрес җаваплар тактага языла: 1б 2а 3в 4б 5а. Тестны дөрес эшләгән укучыларга алкышлыйлар. Укытучы нәтиҗәләрне таблицага тутыра.

**3нче бирем**

**“Тыңла һәм рәсем яса”.** Балалар укытучыны тыңлаганнан соң бүлмә рәсемен ясыйлар.

Мәсәлән: Бу бүлмә. Бүлмәдә өч тәрәзә, ике ишек бар. Өстәлдә сары чәчәк. Диванда кызыл туп. Урындыкта ике яшел китап ята.

Аннары бер-берсенә бүлмәдә нәрсәләр бар икәнен сөйлиләр. Монда өстәмә бирем эшләтергә була. Укытучы укучыларга бүлмәгә тагын нәрсәдәр булса ясап, сөйләргә тәкъдим итә. Мәсәлән, укучы өстәлдә телефон рәсемен ясый, туп янында курчак ясый һәм әйтә: Бу яшел телефон. Ул өстәлдә ята. Бу зур курчак. Ул диванда утыра.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 11. “Ашамлыклар” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, биремле карточкалар, “Укытучылар” һәм “Укучылар” дигән табличкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Рәсем яса” | 2нче бирем “Сүзләр төзе” | 3нче бирем “Укытучылар һәм укучылар” | | 4нче бирем “Сөйлә” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | сораулар | җаваплар | | | |
| | | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Ипи (икмәк), сөт, ит, йомырка, шикәр, тоз, аш, ботка, күмәч, чәй, балык, алма. ... ашыйм / эчәм. ... яратам. ... ашый, ашыйм, ашыйсың”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.
Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:
1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне тиз-тиз әйтергә тиеш. Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.
2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин. (Мәсәлән, саннарны, төсләрне, гаилә темасыннан лексиканы). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.

**1нче бирем**

**“Рәсем яса”.** Укытучы укучыларга алдан әзерләнгән карточкаларны тарата һәм рәсемнең астында язылган ашамлыкларны ясарга тәкъдим итә. Дәреслектән карарга рөхсәт ителми, лексика буенча белемнәре тикшерелә.
I вариант

өч балык

биш яшел алма

яшел аш

II вариант

ике йомырка

алты кызыл алма

көрән шикәр

**2нче бирем**

**“Сүзләр төзе”.** Укытучы бирелгән хәрефләрдән ашамлык белдергән сүзләр төзергә тиеш.

**А О И Т Ш Ө З С К Б Ә**

(сөт, ит, аш, тоз, ботка)

Кем тизрәк сүзләрне таба, шул җиңүче, аңа алкышлыйлар.

**3нче бирем**

**“Укытучылар һәм укучылар” уены.** Укучылар ике командага бүленәләр. Бер команда – “Укучылар”, икенче команда “Укытучылар”. Балалар алдына “Укучылар” һәм “Укытучылар” дигән ике табличка куелып, алар үзләре дә теләгән команданы сайлый ала.

“Укытучылар” “укучылар”дан үзләре теләгән укучыны сайлап, 1-3 сорау бирәләр һәм укучылардан җавап алалар. Мәсәлән:

- Песи балык ашыймы? (Көтелгән җавап: Әйе, песи балык ашый.)
- Песи сөт эчәме? (Көтелгән җавап: Әйе, песи сөт эчә.)
- Песи нәрсә ярата? (Көтелгән җавап: Песи балык, сөт ярата.)
- Син балык (ботка, алма, банан, йомырка һ.б.) яратасыңмы? (Көтелгән җавап: Мин ботка, банан яратам.)
- Син кофе (сөт, чәй, компот һ.б.) эчәсеңме? (Көтелгән җавап: Мин кофе түгел, мин чәй эчәм.)
- Син нәрсә яратасың? (Көтелгән җавап: Мин кызыл алма яратам.)
- .... тәмлеме (ачымы, баллымы)? (Көтелгән җавап: кызыл алма ачы түгел, баллы.)
- Әни кофе, чәй эчәме? (Көтелгән җавап: Әни кофе эчә, лимон белән чәй дә эчә.)
- Әни нәрсә белән чәй эчә? (Көтелгән җавап: Әни лимон һәм кәнфит белән чәй эчә.)
- Ул лимон (кәнфит, шикәр) белән чәй эчәме? (Көтелгән җавап: Әйе, эчә.)
- Әни ботка ашыймы? (Көтелгән җавап: Әйе, әни ботка ашый.)
- Әни нәрсә ярата? (Көтелгән җавап: Әни тәмле ботка, аш, торт ярата.)
- Әти йомырка ашыймы? (Көтелгән җавап: Әйе, әти йомырка ашый.)
- Әти нәрсә ярата? (Көтелгән җавап: Әти ботка, аш, кофе ярата.)
- Холодильникта (суыткычта) сөт (ит, колбаса һ.б.) бармы? (Көтелгән җавап: Суыткычта сөт, колбаса бар.)
- Кем колбаса ярата. (Көтелгән җавап: Песи колбаса ярата.) Һ.б.

Командадагы һәр укучы сорау һәм җавап биреп өлгерергә тиеш. Моны укытучы контрольдә тота. Соңыннан укучылар рольләре белән алышыналар һәм уен дәвам итә. Укучылар авырсынсалар, укытучы алдан үзе сораулар бирә. Аннары укытучы үзен алыштырырга, сыйныфташларына сораулар бирергә тәкъдим итә.

**4нче бирем**

**“Сөйлә”.** Бу бирем теләүчеләр өчен генә. Укучылар үзләре ясаган өч рәсемнән берсен сайлый һәм сөйли. Мәсәлән:

- Бу балык. Балык тәмле. Песи балык ашый. Ул балык ярата. Мин балык түгел, мин аш яратам. Мин аш ашыйм. Ул да тәмле.
- Болар алмалар. Алар кызыл, баллы. Яшел алма баллы түгел. Ул ачы. Мин кызыл алма яратам.
- Бу йомырка. Минем әтием йомырка ярата. Ул иртән шикәр белән чәй эчә һәм йомырка ашый. Мин дә йомырка ашыйм.

- Бу шикәр. Ул ак һәм көрән була. Мин шикәр һәм лимон белән чәй эчәм. Шикәр тәмле, баллы.
- Бу аш. Минем әтием аш ярата. Ул аш ашый. Мин дә аш ашыйм. Һ.б.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 11. “Ашамлыклар” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, биремле карточкалар, “Укытучылар” һәм “Укучылар” дигән табличкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Рәсем яса” | 2нче бирем “Сүзләр төзе” | 3нче бирем “Укытучылар һәм укучылар” | | 4нче бирем “Сөйлә” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | сораулар | җаваплар | | | |
| | | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Ипи (икмәк), сөт, ит, йомырка, шикәр, тоз, аш, ботка, кümәч, чәй, балык, алма. ... ашыйм / эчәм. ... яратам. ... ашый, ашыйм, ашыйсың”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:
1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне тиз-тиз әйтергә тиеш. Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.
2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин. (Мәсәлән, саннарны, төсләрне, гаилә темасыннан лексиканы). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.

**1нче бирем**

**“Рәсем яса”.** Укытучы укучыларга алдан әзерләнгән карточкаларны тарата һәм рәсемнең астында язылган ашамлыкларны ясарга тәкъдим итә. Дәреслектән карарга рөхсәт ителми, лексика буенча белемнәре тикшерелә.
I вариант

| | | |
|---|---|---|
| өч балык | биш яшел алма | яшел аш |

II вариант

| | | |
|---|---|---|
| ике йомырка | алты кызыл алма | көрән шикәр |

**2нче бирем**

**“Сүзләр төзе”.** Укытучы бирелгән хәрефләрдән ашамлык белдергән сүзләр төзергә тиеш.

**А О И Т Ш Ө З С К Б Ә**

(сөт, ит, аш, тоз, ботка)

Кем тизрәк сүзләрне таба, шул җиңүче, аңа алкышлыйлар.

**3нче бирем**

**“Укытучылар һәм укучылар” уены.** Укучылар ике командага бүленәләр. Бер команда – “Укучылар”, икенче команда “Укытучылар”. Балалар алдына

“Укучылар” һәм “Укытучылар” дигән ике табличка куелып, алар үзләре дә теләгән команданы сайлый ала.
“Укытучылар” “укучылар”дан үзләре теләгән укучыны сайлап, 1-3 сорау бирәләр һәм укучылардан җавап алалар. Мәсәлән:

- Песи балык ашыймы? (Көтелгән җавап: Әйе, песи балык ашый.)
- Песи сөт эчәме? (Көтелгән җавап: Әйе, песи сөт эчә.)
- Песи нәрсә ярата? (Көтелгән җавап: Песи балык, сөт ярата.)
- Син балык (ботка, алма, банан, йомырка һ.б.) яратасыңмы? (Көтелгән җавап: Мин ботка, банан яратам.)
- Син кофе (сөт, чәй, компот һ.б.) эчәсеңме? (Көтелгән җавап: Мин кофе түгел, мин чәй эчәм.)
- Син нәрсә яратасың? (Көтелгән җавап: Мин кызыл алма яратам.)
- .... тәмлеме (ачымы, баллымы)? (Көтелгән җавап: кызыл алма ачы түгел, баллы.)
- Әни кофе, чәй эчәме? (Көтелгән җавап: Әни кофе эчә, лимон белән чәй дә эчә.)
- Әни нәрсә белән чәй эчә? (Көтелгән җавап: Әни лимон һәм кәнфит белән чәй эчә.)
- Ул лимон (кәнфит, шикәр) белән чәй эчәме? (Көтелгән җавап: Әйе, эчә.)
- Әни ботка ашыймы? (Көтелгән җавап: Әйе, әни ботка ашый.)
- Әни нәрсә ярата? (Көтелгән җавап: Әни тәмле ботка, аш, торт ярата.)
- Әти йомырка ашыймы? (Көтелгән җавап: Әйе, әти йомырка ашый.)
- Әти нәрсә ярата? (Көтелгән җавап: Әти ботка, аш, кофе ярата.)
- Холодильникта (суыткычта) сөт (ит, колбаса һ.б.) бармы? (Көтелгән җавап: Суыткычта сөт, колбаса бар.)
- Кем колбаса ярата. (Көтелгән җавап: Песи колбаса ярата.) Һ.б.

Командадагы һәр укучы сорау һәм җавап биреп өлгерергә тиеш. Моны укытучы контрольдә тота. Соңыннан укучылар рольләре белән алышыналар һәм уен дәвам итә. Укучылар авырсынсалар, укытучы алдан үзе сораулар бирә. Аннары укытучы үзен алыштырырга, сыйныфташларына сораулар бирергә тәкъдим итә.

### 4нче бирем

**“Сөйлә”.** Бу бирем теләүчеләр өчен генә. Укучылар үзләре ясаган өч рәсемнән берсен сайлый һәм сөйли. Мәсәлән:

- Бу балык. Балык тәмле. Песи балык ашый. Ул балык ярата. Мин балык түгел, мин аш яратам. Мин аш ашыйм. Ул да тәмле.
- Болар алмалар. Алар кызыл, баллы. Яшел алма баллы түгел. Ул ачы. Мин кызыл алма яратам.
- Бу йомырка. Минем әтием йомырка ярата. Ул иртән шикәр белән чәй эчә һәм йомырка ашый. Мин дә йомырка ашыйм.
- Бу шикәр. Ул ак һәм көрән була. Мин шикәр һәм лимон белән чәй эчәм. Шикәр тәмле, баллы.
- Бу аш. Минем әтием аш ярата. Ул аш ашый. Мин дә аш ашыйм. Һ.б.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 12. “Тәнем” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Беренче бирем өчен рәсем, рәсемле карточкалар, уенчыклар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Укучыларга яраткан уенчыклары турында сораулар бирә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Уклар” | 2нче бирем “Табышмаклар” | 3нче бирем “Сөйлә” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар онытканы очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Баш, бит, чәч, күз, колак, борын, авыз, теш, кул, аяк, ... кайда? Чәч нинди? Ничә бармак бар?”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:

1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне берлек һәм күплек саннарда тиз-тиз әйтергә тиеш (мәсәлән: колак – колаклар, күз – күзләр, кул – куллар һ.б.). Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.

2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин (мәсәлән: елга, урман, гаилә, йорт, бүлмә, кыз, малай, төсләр, саннар). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.
3) "Сыйныфташыңны тикшер!". Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: озын, исем, матур, зур, кечкенә, ярат – ул ярата, йокла – ул йоклый, аша – ул ашый, яшә – ул яши, бар, юк һ.б.
Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.
Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.
Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

### 1нче бирем

**"Уклар".** Укытучы укучыларга уклар ярдәмендә сүзләрне рәсем белән тоташтырырга куша. Бу биремне билгеле бер вакыт өчендә эшләргә тиеш булалар, мәсәлән 5 минут бирелә. Тизрәк һәм дөресрәк эшләгән укучыга алкышлыйлар, ул җиңүче була.




### 2нче бирем

**"Табышмаклар".** Тактага номерлар астына дүрт рәсем эленә. Мәсәлән: 1 – Мальвина, 2 – Су анасы, 3 – Карлсон, 4 - Шүрәле яки башка геройлар. Укытучы һәр рәсем турында сөйли, ә укучылар бу герой нинди номерга туры килә, шуны язып куя. Мәсәлән: 4231.

- Аның борыны озын. Колаклары зур. Чәче юк. Ул урманда яши. (Шүрәле)
- Аның чәчләре озын, яшел. Ул елгада яши. (Су анасы)
- Аның ике колагы, ике күзе, бер авызы бар. Аның борыны зур. Ул кәнфит, печенье, торт ярата. Ул түбәдә яши. (Карлсон)
- Ул малай түгел, ул кыз. Ул бик матур кыз. Аның күзләре дә зәңгәр. Ул кечкенә йортта яши. Аның чәчләре озын, зәңгәр. (Пауза) Ул Буратино белән уйный. (Мальвина)

**3нче бирем**

**“Сөйлә”.** Укучыларга үзләренең табышмакларын уйлап әйтергә такъдим ителә. Бирелгән рәсемнәрдәге геройлар яки үзләре алып килгән уенчык геройлары турында сөйләргә кушыла. Мәсәлән: Мырау, Шүрәле, Су анасы, абый, әби, апа, бабай, робот, курчак турында һ.б. Мәсәлән:

- Аның куллары, аяклары бик зур. Ул көрән төстә. Ул тартмада яши. Ул уйный. Ул кем? (Робот)
- Аның күзләре яшел. Аның чәчләре озын. Ул бик матур, яңа. Аның күлмәге кызгылт сары. Ул торт ярата. Ул кечкенә өйдә яши. Ул кем? (Курчак)

Әгәр авыр булса, укытучы сораулар биреп булыша. Мәсәлән: Бу кем/нәрсә? Ул нинди? Ул кайда яши? Ул нәрсә ярата? Һ.б.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 13. “Киемнәр” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, биремле карточкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Мин ... киям” | 2нче бирем “Сораулар” | 3нче бирем “Сөйлә” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер” “Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Кием, пәлтә, чалбар, күлмәк, итәк, башлык, шарф, аяк киеме, ки, бияләй, тун, итек. Мин ... киям. Чалбар нинди? Чалбар акмы? Шарф җылымы? Кайчан кирәк? Җәен/кышын/көзен/язын/ кирәк”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.
Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:
1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне саннар белән тиз-тиз әйтергә тиеш (мәсәлән: җиде шарф, ун бияләй, алты итәк һ.б.). Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.
2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин. (мәсәлән: саннарны, төсләрне, ел фасылларны, гаилә, йорт темаларына караган лексиканы). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.
3) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: миңа кирәк, миңа кирәк түгел, миңа/әнигә килешә, мин киям, ул кия, чалбар урындыкта, тун шкафта, нинди?. кайда?, кайчан?, ничә? һ.б.
Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.
Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.
Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

**1нче бирем**

**“Мин ... киям”.** Укытучы карточкалар өләшә һәм туры килгән сүзләрне язарга куша. Аннары дөреслеген тикшерәләр. Кем тизрәк һәм дөресрәк язып бетерә, шул җиңүче була. Аңа (яки аларга) алкышлыйлар.

- Кыш көне мин _________________ киям.
- Җәй көне мин _________________ киям.
- Яз көне мин _________________ киям.
- Көз көне мин _________________ киям.

**2нче бирем**

**“Сораулар”.** Укытучы сораулар бирә, укучылар чиратлашып җавап бирәләр. Мәсәлән:

- Син нинди кием яратасың?

- Бейсболка җәен кирәкме?
- Ул кышын кирәкме?
- Плащ (тун, шарф, күлмәк, итек) кайчан кирәк?
- Ул сиңа килешәме?
- Ул ничә сум тора?
- Ул нинди?
- Ул кайда?
- Зәңгәр күлмәк урындыктамы?
- Яшел чалбар кайда?
- Ул шкафтамы?
- Әнигә нәрсә кирәк?
- Аның кызыл күлмәге бармы?
- Ул кайда? Һ.б.

Аннары укытучы үзен теләүче укучылар белән алыштыра ала. Нәтиҗәләрне таблицага тутыра.

**3нче бирем**

**“Сөйлә”.** Укытучы һәр укучыны өстәл янына чакыра. Өстәлдә киемнәр темасына рәсемнәр ята. Укучы бер рәсемне сайлап ала, мәсәлән, чалбар сайлый һәм чалбар турында нәрсә белә, шуны сөйли. Авырсынса, укытучы сораулар биреп булыша (сораулар 2нче биремдә). Үрнәкләр:

- Бу чалбар. Ул кышын да, җәен дә кирәк. Мин чалбар яратам. Минем чалбарым сары, бик матур. Ул урындыкта.
- Мин кыш көне кызыл пәлтә киям. Ул матур, җылы. Миңа пәлтә килешә. Пәлтә шкафта.
- Бу кара тун. Ул кыш көне кирәк. Ул бик җылы. Әни тун кия. Ә мин пуховик киям.
- Бу күлмәк. Мин күлмәк киям. Минем күлмәгем кызыл. Ул кечкенә бүлмәдә. Кызыл күлмәк миңа килешә. Һ.б.

**“Бәялә”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 14. “Хайваннар” модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, биремле карточкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем “Йортлар” | 2нче бирем “Табышмаклар” | | 3нче бирем “Сөйлә” | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Җавап | Табышмак | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**“Искә төшер” “Искә төшер”.** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **“Песи, эт, кәҗә, сарык, сыер, ат, аю, куян, төлке, бүре, керпе, тиен”** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:

1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне тиз-тиз әйтергә тиеш. Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.

2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин (мәсәлән: елга, урман, гаилә, өй, йорт, төсләр, саннар). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.


3) “Сыйныфташыңны тикшер!”. Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: йомшак, хәйләкәр, куркак, нәрсә?, ничә?, нинди?, кайда?, нишли?, сикер – ул сикерә, яшә – ул яши, эч – эчә, ярат – ул ярата, бир – ул бирә, сөт, матур һ.б.

Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.

Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр. Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

**1нче бирем**

**“Йортлар”.** Укытучы укучыларга сүзләрне йортларга дөрес урнаштырырга куша. Мәсәлән: песи, куян, аю, ат, эт, керпе, сарык, тиен, сыер. Бу биремне билгеле бер вакыт өчендә эшләргә тиеш булалар, мәсәлән 5 минут бирелә. Тизрәк һәм дөресрәк эшләгән укучыга алкышлыйлар, ул җинүче була.




**2нче бирем**

**“Табышмаклар”.** Укытучы табышмаклар әйтә, укучылар җавап әйтә. Мәсәлән:

- Ул йомшак, бик матур, хәйләкәр. Ул урманда яши. (Төлке)
- Ул йомшак, кара төстә. Ул өйдә яши. Ул сөт эчә. (Песи)
- Ул соры. Ул урманда яши. Ул сикерә. Аның колаклары озын. Ул бик куркак. (Куян)
- Ул да урманда яши. Ул сөт эчә. Ул кечкенә, йомшак түгел. (Керпе)
- Ул зур. Ул ипи ашый. Ул көрән. Аның аяклары озын. Ул урманда түгел, ул фермада яши. (Ат)
- Ул да фермада яши. Ул зур түгел, хәйләкәр дә түгел. Ул үлән ашый. Ул сөт бирә. (Кәҗә)
- Ул бик зур, көрән төстә. Ул фермада түгел, ул урманда яши. Ул бал ярата. (Аю) Һ.б.

Аннан соң теләгән укучыларга үзләренең табышмакларын уйлап әйтергә тәкъдим ителә. Сыйныфташлары табышмакның җавабын әйтсәләр, укучы җиңүче булып санала. Аңа алкышлыйлар. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**3нче бирем**

**“Сөйлә”.** Укытучы һәр укучыны чират буенча өстәл янына чакыра. Өстәлдә хайваннар рәсемнәре ята. Укучы бер хайван рәсемен сайлап ала һәм хайван турында нәрсә белә шуны сөйли. Мәсәлән:

- Сыер рәсеме: Ул бик зур хайван. Ул фермада яши. Ул үлән ашый. Ул сөт бирә.
- Тиен рәсеме: Ул кечкенә, йомшак. Ул урманда яши. Ул кызгылт сары. Ул сикерә. Һ.б.

Әгәр авыр булса, укытучы сораулар биреп булыша. Мәсәлән: Бу нәрсә? Ул нинди? Ул кайда яши? Ул нәрсә ярата? Ул нәрсә ашый/эчә? Һ.б. Укытучы укучыларның җавапларын бәяләп бара. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**"Бәялә".** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- ✓ Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- ✓ Кем нәрсә эшли алмады?
- ✓ Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- ✓ Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- ✓ Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- ✓ Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

## 15. "Туган көн" модуле

**Көтелгән нәтиҗә**

Өйрәнгәннәрне гамәли куллана алу.

Шәхесара һәм мәдәниятара татар теленә карата ихтирамлы булу һәм аны яхшы өйрәнергә теләү.

Аралаша белү сәләтенә ия булу.

**Җиһазлар**

Рәсемле карточкалар, биремле карточкалар, "Укытучылар" һәм "Укучылар" дигән табличкалар.

Укытучы укучылар белән исәнләшә, хәлләр сораша. Сыйныфта кем бар, кем юклыкны тикшерә. Бу дәрестә командаларга бүленеп эшләячәкләрен әйтә.

Укытучы тикшерү дәресендә һәр укучыга игътибар итәргә һәм аның эшен бәяләп барырга тиеш. Моның өчен, сыйныфтагы укучылар исемлеге язылган махсус таблицаны алдан ук әзерләп кую сорала.

| Укучының исеме һәм фамилиясе | 1нче бирем "Кояш" | | 2нче бирем "Текст белән эш" | 3нче бирем "Укытучылар һәм укучылар" | Авазларның әйтелеше | Нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сүзләр | Җөмләләр | | | | |
| | | | | | | |

+ җавап дөрес, ~ җавап төгәл түгел яки озак көтелгән булу, - хата булу

**"Искә төшер".** Укытучы укучылардан алдагы дәресләрдә татарча нинди сүзләр, гыйбарәләр өйрәнүләрен сорый. Укучылар, кул күтәреп, җавап бирәләр. Укучылар оныткан очракта, укытучы да аларга ярдәм итәргә мөмкин. **"Бәйрәм, туган көн, кунак**, **ял ит, кунакка бар, теләк, телә, бүләк ит, күңелле, котла. Туган көнең белән! Бәйрәм белән!"** кебек сүз һәм гыйбәрәләр барысы да кабатланып чыгарга тиеш.

Бу эшне түбәндәгечә дә башкарырга мөмкин:
1) укытучы рәсем күрсәтә, ә укучылар чылбыр буенча тиешле сүзне тиз-тиз әйтергә тиеш. Җавап бирергә авырсынган укучы чылбырдан төшеп кала һәм индивидуаль рәвештә җавап бирә, калган укучылар булыша ала.
2) укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар тәрҗемә дөрес булса **1** дип, ә дөрес булмаса – **0** дип язып куя. **0** һәм **1** саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 тәрҗемәдән 4се дөрес түгел. Монда элек үтелгән, ләкин бу дәрес өчен кирәк булган лексиканы кертергә мөмкин (мәсәлән, саннар, гаилә, ашамлыклар, уенчыклар темаларыннан лексиканы). Бу этапта хаталарны төзәтергә һәм юнәлеш биреп җибәрергә була.
3) "Сыйныфташыңны тикшер!". Бу күнегүдә рәсемдә булмаган сүзләрне дә кабатларга кирәк, чөнки аларны дәрестә кулланырга тиеш булалар: кайчан? ничә? нинди? кайда? нишли? нишлиләр? исем, матур, күңелле, шат, кирәк, уйныйлар, җырлыйлар, котлыйлар, әйтәләр, ашыйлар, эчәләр, киләләр, бүләк итәләр, бирәләр һ.б.
Һәр укучыга өчкә бөкләнгән бит бирелә (10 см х 10 см). Битнең өске өлешендә сүз татарча язылган була. Битнең аскы өлешендә сүзнең тәрҗемәсе әйләндерелеп языла. Битнең уртасы буш кала.
Балалар басалар, парлашалар, җилкәдәш сыйныфташлары белән лексиканы кабатлыйлар, битләр белән алмашыналар һәм икенче парны табарга китәләр.
Башта сүзләрне татар теленнән рус теленә тәрҗемә итәләр, аннан соң битләрне әйләндерәләр һәм рус теленнән татар теленә тәрҗемә итәләр.

### 1нче бирем

**"Кояш".** Укытучы укучыларга кояш рәсемнәре бирә һәм нурларга туган көн темасына караган сүзләр язарга куша. Соңыннан шул сүзләр белән җөмләләр төзиләр. Бу биремне парлап та, командалап та эшләргә була. Иң матур һәм дөрес җөмләләр әйткән укучыларга алкышлыйлар.

### 2нче бирем

**"Текстны белән эш".** Укытучы укучыларның таныш булмаган текстның эчтәлеген дөрес аңлап, биремнәрен дөрес эшли алуларын тикшерә.

### Кунакта

Бу малай. Аның исеме Аяз. Бүген 7нче май, аның туган көне. Аның дуслары күп. Алар кунакка киләләр. Бәйрәм белән котлыйлар, уечыклар бүләк итәләр. Аяз аларга рәхмәт әйтә. Кунаклар уйныйлар, җырлыйлар.
Әни тәмле торт пешерә. Кунаклар кәнфит һәм торт белән чәй эчәләр. Әнигә рәхмәт әйтәләр. Тагын уйныйлар, җырлыйлар. Бәйрәмдә күңелле. Аяз бик шат.

Биремнәр:

Һәр укучы 1) текстны сәнгатьле укый; 2) бер җөмләгә сораулар уйлый, мәсәлән: *Әни тәмле торт пешерә.*

Кем тәмле торт пешерә?

Әни нинди торт пешерә?
Әни нәрсә пешерә?
Әни нишли?
Әни тәмле торт пешерәме?

3) текстка туры килмәгән җөмләләрне таба:

- Бүген сигезенче май.
- Дуслар кунакка киләләр.
- Алар китаплар бүләк итәләр.
- Торт бик тәмле.
- Әни рәхмәт әйтә.
- Бәйрәмдә күңелле түгел.

**3нче бирем**

**“Укытучылар һәм укучылар” уены.** Укучылар ике командага бүленәләр. Бер команда – “Укучылар”, икенче команда “Укытучылар”. Балалар алдына “Укучылар” һәм “Укытучылар” дигән ике табличка куелып, алар үзләре дә теләгән команданы сайлый ала.

“Укытучылар” “укучылар”дан үзләре теләгән укучыны сайлап, 1-3 сорау бирәләр һәм укучылардан җавап алалар. Мәсәлән:

- Сиңа ничә яшь? (Көтелгән җавап: Миңа җиде яшь.)
- Туган көн кыш көнеме? (Көтелгән җаваплар: Әйе, кыш көне./Юк, кыш көне түгел.)
- Кунакка бабай белән әби киләме? (Көтелгән җавап: Әйе, килә.)
- Кунакка тагын кем килә? (Көтелгән җавап: Тагын дуслар/апа килә.)
- Уенчыклар бүләк итәләрме? (Көтелгән җавап: Әйе, уенчыклар бүләк итәләр.)
- Сиңа нинди бүләкләр бирәләр? (Көтелгән җавап: Китаплар, чәчәкләр, телефон, чалбар, күлмәк һ.б. бүләк итәләр.)
- Кем торт пешерә? (Көтелгән җавап: Әни/әби торт пешерә.)
- Кем торт ашый/ярата? (Көтелгән җавап: Кунаклар, балалар торт ашый/ярата.)
- Син торт яратасыңмы? (Көтелгән җавап: Мин дә торт яратам.)
- Бәйрәмдә күңеллеме? (Көтелгән җавап: Бәйрәмдә бик күңелле.)
- Кем рәхмәт әйтә? (Көтелгән җавап: Кунаклар рәхмәт әйтә.Мин дә рәхмәт әйтәм.)
- Кемгә рәхмәт әйтәсең? (Көтелгән җавап: Мин әнигә/әтигә/әбигә рәхмәт әйтәм.)
- Бәйрәмнәр кирәкме? (Көтелгән җавап: Бәйрәмнәр бик кирәк.)
- Кемнәргә бәйрәмнәр кирәк? (Көтелгән җавап: Балаларга/кунакларга бәйрәмнәр кирәк.)
- Сиңа бәйрәмнәр кирәкме? (Көтелгән җавап: Миңа да бәйрәмнәр кирәк.) Һ.б.

Командадагы һәр укучы сорау һәм җавап биреп өлгерергә тиеш. Моны укытучы контрольдә тота. Соңыннан укучылар рольләре белән алышыналар һәм уен дәвам итә. Нәтиҗәләр таблицага тутырыла.

**“Бәяләү”.** Укытучы, укучыларга сораулар биреп, бүгенге дәрестәге эшне бәяләргә куша. Сораулар татарча да, русча да яңгырый. Укучылар, әлбәттә, русча җавап бирә алалар.

- Дәрестәге эшегезгә нинди бәя куярсыз?
- Кем нәрсә эшли алмады?
- Сез үзегезне нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сыйныфташларыгызны нәрсә өчен мактый аласыз?
- Сезнеңчә, дәрестә кем башкалардан яхшырак эшләде?
- Бер-берегезне мактагыз.

Укытучы сыйныфтагы укучы исемлеге язылган максус таблицага укучыларның балларын куеп бәяли. Укучылар белән саубуллаша һәм уңышлар тели.

# Тикшерү эшләре

## 1—4 нче модульләр

➔ **Лексиканы тикшерү.** Укытучы билгеле бер тәртиптә рәсемнәр (1-3 модульдән) күрсәтә, ләкин кайберләрен дөрес атамый. Укучылар сүз дөрес булса 1 дип, ә дөрес булмаса – 0 дип язып куя. 0 һәм 1 саннарыннан торган тезмә барлыкка килә. Мәсәлән, 1100111010. Димәк, 10 сүзнең 4се дөрес түгел.

➔ **Дөрес буя.**




кызыл шәмәхә кара яшел зәңгәр

➔ **Цифр белән яз.**

......... ......... ......... ......... ......... ......... .........
сигез ун дүрт җиде өч алты ике

➔ **Сүзне рәсем белән тоташтыр.**





китап
дәфтәр
өстәл




# Тикшерү эшләре

## 5—7 нче модульләр


### I вариант

**➔ Сүзләрне йортларга дөрес урнаштыр.**




әби курчак уенчык сеңел
бөтерчек утыр шакмак

**➔ Сүзне рәсем белән тоташтыр.**



курчак быргы абый әби

**➔ Боеруларны ✕ тамгасы белән билгелә.**

___ Аша! ___ Ул ашый. ___ Эч!


___ Ул укый. ___ Ул керә. ___ Бас!

**➔ Марат нишли? Сөйлә.**

Җырла! Рәсем яса! Кер! Утыр! Чык! Сөрт!


### II вариант

**➔ Сүзләрне йортларга дөрес урнаштыр.**




әни машина эне уен
туп апа җырла

**➔ Сүзне рәсем белән тоташтыр.**



шакмак бабай туп очкыч

**➔ Боеруларны ✕ тамгасы белән билгелә.**

___ Ул карый. ___ Кит! ___ Ул сөртә.

___ Ул җырлый. ___ Рәсем яса! ___ Кер!

**➔ Марат нишли? Сөйлә.**

Тукта! Эч! Яз! Тыңла! Әйт! Кил!

# Тикшерү эшләре

## 8—10 нче модульләр

### I вариант

**→ Сәгать ничә?**



Сәгать ...

Мин ...



Сәгать ...

Мин ...



Сәгать ...

Мин ...

**→ Тәрҗемә ит.**

урам — урамнар — ике урам
сигез тәрәзә — тәрәзә — тәрәзәләр
ай — тугыз ай — айлар

**→ Артык сүзне тап, астына сыз.**

| | | |
|---|---|---|
| яз | ишек | кибет |
| күз | елга | урам |
| кат | тәрәзә | бина |
| җәй | бүлмә | сәгать |

**→ Парларны тап, уклар белән тоташтыр.**

| | |
|---|---|
| биек | юл |
| дүрт | кат |
| тар | бина |

### II вариант

**→ Сәгать ничә?**



Сәгать ...

Мин ...



Сәгать ...

Мин ...



Сәгать ...

Мин ...

**→ Тәрҗемә ит.**

бүлмә — бүлмәләр — җиде бүлмә
алты бина — бинада — биналар
сәгатьләр — сәгать — дүрт сәгать

**→ Артык сүзне тап, астына сыз.**

| | | |
|---|---|---|
| җиһаз | көндез | шәһәр |
| караватөй | өй | авыл |
| йорт | кичен | иртән |
| кыш | сәгать | бина |

**→ Парларны тап, уклар белән тоташтыр.**


| | |
|---|---|
| киң | сәгать |
| биек | урам |
| ун | йорт |

# Тикшерү эшләре

## 11—13 нче модульләр

### I вариант

➔ **Сүзләрне йортларга дөрес урнаштыр.**




тун йомырка борын авыз итәк
шикәр ит теш бияләй бүлмә

➔ **Тәрҗемә ит.**


күлмәк — күлмәкләр — җиде күлмәк
ике колак — колагым — колаклар
балыклар — балык — өч балык

➔ **Кирәк сүзләрне яз.**

Минем ... бар. Ул бик ... . Ул ... сум тора. Шкафта тагын ... бар. Минем ... юк. Миңа ... кирәк. Ул ... төстә. Ул миңа килешә.

### II вариант

➔ **Сүзләрне йортларга дөрес урнаштыр.**




аш итек чәч урман бит аяк сөт
башлык алма пәлтә

➔ **Тәрҗемә ит.**

кул — куллар — ике кул
сигез чалбар — чалбарым — чалбарлар
боткалар — боткада — ботка

➔ **Кирәк сүзләрне яз.**

Минем ... бар. Ул бик .... Ул ... сум тора. Шкафта тагын ... бар. Минем ... юк. Миңа ... кирәк. Ул ... төстә. Ул миңа килешә.

# Тикшерү эшләре

## 14—15 нче модульләр

### I вариант

**➔ Яшел карандаш белән «Туган көн» темасына караган сүзләрне әйләндереп ал.**

бәйрәмдә сыйныфта бүләк итә

күңелле котлый матур кечкенә ашый

кунакта аю кызыл дуслар

**➔ Кайда? Нинди? Нишли? Соруларына җавап биргән сүзләрне күчереп яз.**

| кайда? | нинди? | нишли? |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |

**➔ Һәр сүзгә пар тап.**

| бәйрәм | күлмәк | аяк киеме | куян |
|---|---|---|---|
| ... | ... | ... | ... |

(сары, ак, күңелле, җылы, тәмле)

**➔ Кирәкле сүзләрне куеп, үз хайваның турында сөйлә.**

| | |
|---|---|
| Минем ... бар. | (нәрсә?) |
| Аның исеме ... . | (ничек?) |
| Аңа ... яшь. | (ничә?) |
| Ул ... төстә. | (нинди?) |
| Тагын ул ... . | (нинди?) |
| Ул ... ярата. | (ярата?) |

**➔ Сорауларга җавап бир.**

Бүген нинди бәйрәм?

Кунакка кем килә?

Бәйрәмдә күңеллеме?

### II вариант

**➔ Яшел карандаш белән «Туган көн» темасына караган сүзләрне әйләндереп ал.**

курчак керпе бәйрәм туган

көн ял итә зур кара тели торт

матур яза рәхмәт

**➔ Кайда? Нинди? Нишли? Соруларына җавап биргән сүзләрне күчереп яз.**

| нәрсә? | нинди? | нишли? |
|---|---|---|
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |
| ... | ... | ... |

**➔ Һәр сүзгә пар тап.**

| курчак | кунак | песи | бүләк |
|---|---|---|---|
| ... | ... | ... | ... |

(яшь, яшел, кара, матур, зур)

**➔ Кирәкле сүзләрне куеп, үз хайваның турында сөйлә.**

| | |
|---|---|
| Минем ... бар. | (нәрсә?) |
| Аның исеме ... . | (ничек?) |
| Аңа ... яшь. | (ничә?) |
| Ул ... төстә. | (нинди?) |
| Тагын ул ... . | (нинди?) |
| Ул ... ярата. | (ярата?) |

**➔ Сорауларга җавап бир.**

Әни торт пешерәме?

Торт нинди?

Кем торт ашый?

# Тикшерү эшләре

## Еллык контроль эш

### I вариант

→ **«Нәрсә?» соравына җавап биргән сүзләрнең астына кызыл карандаш белән сыз.**

кием кунак күңелле песи апа котла
сыер такта эне рәхмәт абый бәйрәм
авыл колак әби сары әни хуҗа юл киң

→ **Гаилә әгъзаларын тап. Яшел карандаш белән билгелә.**

кием кунак күңелле песи апа котла сыер
такта эне рәхмәт абый бәйрәм авыл колак
әби сары әни хуҗа юл киң

→ **Парларны тап.**

| | |
|---|---|
| Бәйрәм | кара |
| Песи | кечкенә |
| Дәфтәр | күңелле |
| Кул | яшел |
| Сеңел | ике |

**Үзең турында яз.**

→ Мин … .
Миңа … яшь.
Мин … яшим.
Минем … бар.
Ул бик … .
Мин … яратам.
Мин … ашыйм.
Шкафта … бар.
Ул … сум тора.
Кышын мин … киям.

### II вариант

→ **«Нәрсә?» соравына җавап биргән сүзләрнең астына кызыл карандаш белән сыз.**

кием кунак күңелле песи апа котла сыер
такта эне рәхмәт абый бәйрәм авыл колак
ат сары әни хуҗа керпе киң

→ **Гаилә әгъзаларын тап. Яшел карандаш белән билгелә.**

кием кунак күңелле песи апа котла сыер
такта эне рәхмәт абый бәйрәм авыл колак
ат сары әни хуҗа керпе киң

→ **Парларны тап.**

| | |
|---|---|
| Күбәләк | җылы |
| Бина | яшел |
| Тун | сары |
| Такта | күңелле |
| Көн | биек |

**Үзең турында яз.**

→ Мин … .
Миңа … яшь.
Мин … яшим.
Минем … бар.
Ул бик … .
Мин … яратам.
Мин … ашыйм.
Шкафта … бар.
Ул … сум тора.
Кышын мин … киям.